КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 16 март г.Казань № 243

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Кызыл китабын алып бару турындагы нигезләмәне раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану хакында» 2018 ел, 19 апрель, 262 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Кызыл китабын алып бару турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Кызыл китабын алып бару турындагы нигезләмәне раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану хакында» 2018 ел, 19 апрель, 262 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Кызыл китабын алып бару турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктка «әйләнә-тирә мохитне саклау һәм хайваннар дөньясын һәм аның яшәү мохитен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендәге законнар нигезендә» сүзләрен өстәргә;

2.1 пунктта:

өченче абзацта татар текстында «мониторинг» сүзен «дәүләт мониторингын» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацка «дәүләт мониторингы мәгълүматлары һәм басылып чыккан фәнни мәгълүматлар (санның фәнни бәяләүләре) нигезендә» сүзләрен өстәргә;

2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Татарстан Республикасы Кызыл китабына хайваннар дөньясы объектларын кертү турындагы тәкъдимнәр, шулай ук нигезли һәм аңлатма бирә торган материаллар (дәүләт мониторингы мәгълүматлары, фәнни мәгълүматлар) Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты тарафыннан тиешле карар кабул ителгән көнгә кадәр кимендә 180 көн алдан вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

«Хайваннар дөньясы турында» 1995 елның 24 апрелендәге 52-ФЗ номерлы Федераль законның 34 статьясындагы беренче өлешенең икенче абзацында каралган хайваннар дөньясы объектларыннан файдалану төре гамәлгә ашырыла торган сирәк һәм юкка чыгу куркынычы яный торган хайваннар дөньясы объектларын Татарстан Республикасының Кызыл китабына керткән очракта, мәҗбүри тәртиптә аларның популяцияләре санының табигый тирбәнешләре исәпкә алына һәм яшәү (ареал) чикләре күрсәтелә.

Хайваннарның, үсемлекләрнең яки гөмбәләрнең теге яки бу төрен Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертү турындагы мәсьәләләрне карап тикшерү, шулай ук тиешле карарларны кабул итү Комиссия тарафыннан гамәлгә ашырыла. Комиссия тарафыннан кабул ителгән карар Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты боерыгы белән раслана.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин